**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2022 елның 03 ноябре** **№ 10**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 17 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Комар авылы, Лесная урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында үткәрергә

2. «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман, Яшьләр урамы юлларына вак таш җәю , ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Яңа Комар авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү, ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Ошторма Юмья авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев